ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

29.11.2024 г.Казань № 344-17/т-2024

Әбсәләм авылының «Әбсәләм төзелеш конструкцияләре һәм материаллары комбинаты» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенең 2025 елга керү тимер юлларында күрсәтелә торган транспорт хезмәтләренә максималь дәрәҗәдә чик тариф билгеләү турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Бәяләрне (тарифларны) дәүләт тарафыннан җайга салуны тәртипкә китерү чаралары турында» 1995 елның 7 мартындагы 239 номерлы карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 29.11.2024 ел,

№29-ПР идарә утырышы беркетмәсе нигезендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Әлеге карар кушымтасына туры китереп, Әбсәләм авылының «Әбсәләм төзелеш конструкцияләре һәм материаллары комбинаты» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте тарафыннан керү тимер юлларында күрсәтелә торган транспорт хезмәтләренә максималь дәрәҗәдә чик тариф билгеләргә.

2. Әлеге карарның 1 пунктында билгеләнгән иң чик максималь тариф 2025 елның 1 гыйнварыннан 2025 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

3. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис А.С.Груничев

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
29.11.2024 № 344-17/т-2024
карарына кушымта

Әбсәләм авылының «Әбсәләм төзелеш конструкцияләре һәм материаллары комбинаты» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте тарафыннан керү тимер юлларында күрсәтелә торган транспорт хезмәтләренә максималь дәрәҗәдә чик тариф

I бүлек. Чик дәрәҗәдә максималь тариф

| Тәртип саны | Хезмәтләр төре | Үлчәү берәмлеге | Тариф, сумнарда (өстәмә хак салымын исәпкә алмыйча) |
|---|---|---|---|
| 1. | 1 км ераклыкка йөк алып бару | 1 тонна | 35,72 |

2 бүлек. Башка шартлар

1. Сәнәгый тимер юл транспорты предприятиесе тарафыннан башкарыла торган эшләргә һәм хезмәтләргә I «Чик дәрәҗә максималь тарифлар» бүлегендә каралмаган тарифлар Россия Федерациясе Транспорт министрлыгының 2001 елның 20 декабрендәге АН-104-р номерлы боерыгы белән расланган Сәнәгый тимер юл транспортында башкарыла торган эшләргә һәм хезмәтләргә тарифлар һәм җыемнар формалаштыру буенча методик күрсәтмәләр нигезендә якларның килешүендә билгеләнә.

2. Йөк ташу һәм төяп җибәрү-бушату эшләре өчен түләү заказчыдан ташылган йөкнең фактик авырлыгы өчен алына.

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт
комитетының тариф карарларын кабул итүне
оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге